**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__31__» ___03_____ 2025 ел.** **№ __66____**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 04 мартындагы 59 номерлы «Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 04 мартындагы 59 номерлы «Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә (13.01.2023 №2, 27.10.2023 №279 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. пунктының 2.1.в) подпунктын , яңа редакциядә бәян итәргә:

"в) административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре Федераль законның 13 статьясындагы 13.1 - 15 өлешләрендә күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртипләрендә каралган очракларда күрсәтелгән бүлек административ регламент структурасына кертелмәскә мөмкин;»;

1.2. 2.1 пунктының г) д) пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2.3 пунктының 1.3 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.3. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлеге түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

1) муниципаль хезмәт исеме;

2) муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган исеме;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге;

6) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;

8) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары;

9) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, мөрәҗәгать итүче турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органга яисә күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта чиратта көтүнең максималь срогы;

10) муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен теркәү срогы;

11) муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге булган мәгълүмат стендларына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә таләпләр;

12) муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану һәм аның сыйфаты күрсәткечләре;

13) муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

- күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алу;

- муниципаль хезмәт турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирү турында.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары О.Н. Газизова